Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
30.01.2026 ел №5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселокта җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2026 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогыбашкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча 9 678,63 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен кушымталар нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Үз көчен югалткан дип таныргга:

- «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 29.01.2025 ел, № 19 карары.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Галлямов

(М.П.: РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН / ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ / ОГРН 1061687003069 / Исполнительный комитет поселка городского типа Джалиль / Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты / ИНН 1636005574)

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлилшәһәртибындагыпоселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2026 елның 30 гыйнвар
5 номерлы карарына 1 кушымта

Бәясе
җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан иренә, якын туганнарына, башка туганнарына, законлы вәкиленә яисә вафат булган кешене җирләү бурычын үз өстенә алган башка затка күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегеннән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының “Җәлил шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегендә
01.02.2026 елдан

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4 170,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | 9 678,63 |

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесенең
2026 елның 30 гыйнвар
5 номерлы карарына 2 кушымта

Бәясе
үлгән кешенең тормыш иптәше, якын туганнары, бүтән туганнары йә законлы вәкиле булмаганда яисә алар тарафыннан җирләү мөмкинлеге булмаганда, шулай ук үлгән кешене өйдә, урамда яисә Эчке эшләр органнары тарафыннан билгеләнгәннән соң җирләү, җирләү бурычын үз өстенә алган башка затлар булмаганда җирләү мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан күрсәтелә торган җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлегенең шәхесләр,
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының "Җәлил шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлегендә
01.02.2026 елдан

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе-(сум.) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | - |
| 2. Кәфенләү | 1 500,00 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2670,37 |
| 3.Мәетнең гәүдәсен (гәүдә калдыкларын) зиратка күчерү | 1 913,26 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3 595,00 |
| Барлыгы | 9 678,63 |